# Мәктәп хәбәрчесе

**№1**
**(№62)**
**гыйнвар 2025 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**





***/Мөхәррир минбәре/***

## *Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе Җитсен иде һәрбер күңелгә...*

Һәр төбәкне үзенең күренекле шәхесләре билгели. Районыбыздан чыккан мондый шәхесләр арасында тыйнак кына иҗаты белән Хәсән Туфан тора. Тыйнак диюем иҗат эше аз булганнан түгел, ә салмаклык, сабырлык белән тулган шигырьләре шулай билгели аны. Туган ягына булган яратуы, аннан читтә яшәргә мәҗбүр булуы сыкраулар булып иҗатына тула. Аның шигъри тезмәләре һәрбер ир кешенең Ватанга карата йөрәгендә саклангн олы мәхәббәтне ача.

2025 нче елда фаҗигале язмышлы олуг язучының тууына 125 ел тула. Шул уңайдан районыбызда **Хәсән Туфан елы** дип игълан ителде. Иске Кармәт авылы биргән якташыбызның тормышын, әдәби мирасын, фаҗигале елларын тагын бер кат укучыларыбызга җиткерәсебез килә. 16 ел буе туган җиреннән еракта яшәргә мәҗбүр булган Хәсән ага Туфанга бирелгән түземлелекне, нинди очракта да кешелекле булып калуын һәрберебезгә үрнәк итеп алырлык. Шул 1940—1956 елларда ул хаксызга төрмәгә утыртылуы, сөргенгә сөрелүе аркасында әдәбияттан аерылып тора, 1956 елның җәенә яңадан Казанга кайта һәм аның иҗаты тагын бөтен таланты белән ачылып китә. Шагыйрь гомеренең соңгы көненә кадәр (ул 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды) иҗади хезмәтен туктатмый, яңадан-яңа әсәрләр язуын дәвам итә.

Менә шундый авырлыклардан соң да рухын сындырмаган әдипне искә алып, укучыларыбызда туган телгә, туган җиргә мәхәббәтне үстерә алсак, эшебез нәтиҗәле булыр дип ышанабыз.

***Фәнүзә Гафиятуллина, баш мөхәррир***




***/Мөгаллим киңәше/***

## *Бөек шәхесләр үрнәгендә балаларга тәрбия бирү*

29 нчы гыйнварда бөек рус язучысы, кыска хикәя һәм психологик пьессалар остасы, публицист, табиб, хәйрияче, дөньякүләм әдәбиятның гомум танылган классигы Антон Павлович Чеховның тууына 165 ел булды. Шул уңайдан мәктәптә 5 нче һәм 7 нче сыйныф укучылары өчен "Чехов белән бергә көләбез" дигән кичә оештырылды. Бу чараның төп максаты – укучыларда әдәбиятка кызыксыну уяту һәм кешелекнең мөһим сыйфатларын үстерү булып тора.

Билгеле булганча, А.П.Чехов бик иртә мөстәкыйльлеккә дучар була. Әти-әнисе Мәскәүгә күченгәннән соң, ул укуын тәгәлләр өчен, туган шәһәрендә берүзе калырга мәҗбүр була. Түләүле дәресләр биреп тормышын алып бара, шул ук вакытта тырышып укый. Үзен генә тәэмин итеп калмый, әниләренә дә акчалата ярдәм җибәреп тора. Гимназияне уңышлы гына тәмамлагач, язучы Мәскәү университетының медицина факультетына укырга керә. Студент елларында Чехов акча эшләвен һәм үз әсәрләрен язуын дәвам итә. Ата-анасына, туганнарына булышуын туктатмый.

Антон Павлович үз туганнарына карата гына түгел, ә үзе дәвалаган авыруларга да ягымлы һәм ярдәмчел була. Мөмкинлекләре булган авыруларны бушлай дәвалый. Чехов крестьян балалары өчен өч мәктәп ача һәм туберкулез белән авыручылар дәваланган хастаханә һәм шифаханәләрне спонсорлык итә. Күргәнебезчә, үзенең кыска гомере эчендә Чехов бик күп яхшы һәм файдалы эшләр башкарган.

Үзенең күпсанлы әсәрләрендә Чехов еш кына ялкаулыкны һәм ахмаклыкны мыскыл итә, үз фикереннән мәхрүм булганнардан көлә. Уздырылган чарада укучылар бөек язучының иҗатын тирәнтен белүләрен һәм әсәрләрне дөрес анализлый алуларын күрсәттеләр. Бу исә, безнең балаларыбызның чын кеше нинди булырга тиешлеге турындагы дәресне үзләштерүләре хакында сөйли.

Уздырылган чара Чеховка хөрмәт күрсәтү генә түгел, яшь буынга әхлакый тәрбия бирүдә дә мөһим адым булды, дип уйлыйбыз. Бу бөек шәхес үрнәге яшь укучыларыбызны алга таба да тырыш булырга һәм бөек максатларга омтылырга рухландырсын иде.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***



***/Мәктәп тормышы/***

## *Блокада хатирәсе*

27нче гыйнварда ел саен Ленинград блокадасының тәмамлануы көнен билгеләп үтәбез. 1941-1944нче елларда 900 көн дәвам иткән блокада ленинградчыларга күпме авырлык китергәнен барыбыз да беләә. Укучыларыбызга Бөек Ватан сугышы елларындагы бу фаҗига турында һәр елны искәртеп торабыз. Ул елларның авырлыгын, ризыкка тилмерүләрен хәзерге буынга күрергә, белергә язмасын дип телибез ул дәресләрдә.

***Олеся Пискарева, директор киңәшчесе***

***/Безнең спорт/***

## *Шахматлы гыйнвар*




7нче гыйнвар көнне, барлык укучылар да кышкы каникул ялларын дәвам иткән вакытта, шахматчыбыз Фаил Гафиятуллин Аксубай районының Яшьләр үзәгендә узган Татарстан Республикасының физик культура эшлеклесе Горбунов Валерий истәлегенә багышланган XII шахмат турнирында катнашты. Турнирда Аксубай, Норлат, Чистай, Әтнә, Казан шахматчылары көч сынашты. Уен нәтиҗәсе буенча Фаил абсолют беренчелекне башкаларга бирмәде. Кубок, грамота, медаль, акчалата приз белән бүләкләнде.


19нчы гыйнварда Фаил Татарстан Республикасының шахматның рапид төре буенча Гран Приенең IV этабында, 18 яшькәчә шахматчылар арасында II урын алды. Котлыйбыз, Фаил!!! Киләчәктә дә зурдан-зур уңышларга ирешүеңне телибез.

***/Күңелле тәнәфес/***

**Дөрес җавапны табыгыз**




**Бер йөрештән мат куя аласызмы? Аклар йөри.**



***/Котлыйбыз!/***



Гыйнвар аенда дөньяга килгән дусларыбыз **Хәйруллин Мансур**, **Галиәскәрова Айшә**, **Залиев Ильфир** һәм **Закирова Ләйсәнне** туган көннәре белән котлыйбыз! Аларга ныклы сәламәтлек, көчле ихтыярлы, максатчан, тырыш укучылар булып үсүләрен телибез.

Мәктәп хезмәткәрләреннән физика-информатика укытучысы **Хөснуллин Фәнис абыйны** гомер бәйрәмнәре белән котлап, тормыш иминлеге, сәламәтлек, озын гомер теләп калабыз.


**<u>Газетаны гамәлгә куючы</u> – Түбән Майна урта мәктәбе**
**<u>Мөхәррир</u> – Фәнүзә Гафиятуллина**
**<u>Редколлегия әгъзалары:</u> Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин**



## Канатлы дусларга ярдәм

Балаларда кошларга карата экологик белемле мөнәсәбәт формалаштыру максатыннан чыгып, 13нче гыйнвар көнне мәктәбебездә тәрбия сәгате үткәрелде. Башлангыч сыйныф балалары белән кышның кошлар тормышы өчен бик авыр ел фасылы булуы һәм нинди кошлар, ничек итеп бу кыенлыкларны җиңеп чыгулары турында әңгәмә үткәрелде. Укучылар ни өчен кайбер төр кошларның җылы якка китүләре турында белделәр. Кошларны танып белү уены үткәрелде.

Балалар тирә-юньгә битараф булмыйча, нәни дусларыбызны сөеп, аларга карата мәрхәмәтлелек хисләре белән үсәләр. Кышын туган якларда үткәрүче кошларга авыр икәнен беләбез. Алар турында онытмыйча, ризык белән ярдәм итәргә тырышабыз. Бу игелекле эшебез ел саен дәвам итеп килә. Барыбыз да кошларга җимлекләр ясап элдек.

***Рузилә Хәйруллина, башлангыч сыйныф укытучысы***

---

## Интернетсыз бер көн



Хәзерге вакытта истәлекле һәм үзенчәлекле даталар көн саен диярлек билгеләп үтелә. Гыйнварның соңгы якшәмбесе **"Интернетсыз бер көн"** дип атала. Халыкны интернеттан тыеп торырга өндәгән бу чараның максаты бер генә көн булса да, кешеләрнең бер-берсе белән җанлы аралашуына ирешүне күздә тота. Өлкәннәрне дә, бигрәк тә балаларны, шул кечкенә тартмадан башка яшәп карарга чакыру көне.



Телефон ватылып торган арада көннең никадәр файдалы узганын кемнең уйлаганы бар икән? Өйдә дә, мәктәптә дә җылы сөйләшүләр сирәк булган, хәрәкәтле уеннарның бөтенләй диярлек булмаган заманда бу көн – бәйрәм. Элек телефоннар өйләрдә дә сирәк булганда, кеше аңа бәйле түгел иде. Хәзер исә, телефоннар кесә саен, һәм күп кеше нигәдер шуңа бәйләнгән. Телефонны минутка да кулдан куймыйча, нидер югалтырбыз кебек йөрибез.

Менә шул билгеләнгән көндә без балалар белән хәрәкәтле уеннар уйнап, бергә булуның, хәрәкәтләнеп уйнауның нинди кызык икәнен күрсәттек. Үзләре дә бик шатланып уйнадылар. Экранга текәлеп, вакытны бушка уздыру сәламәтлеккә зыян сала, дигән фикердә мин. Һәр нәрсәнең чамасы булырга тиеш икәнен нәкъ менә шушы интернетсыз бер көн аңларга мөмкинлек бирер.

***Олеся Пискарева, директор киңәшчесе***

---

## Китапханәдә кунакта

Безгә мәктәптә укытучы апалар да, өйдә әниләр дә, һәрдаим китап уку кирәклеген сөйләп торалар. Ә беркөнне безне апалар яңа китаплар белән таныштыру өчен, үзебезнең авыл китапханәсенә алып керделәр.




Китапханәче Рузилә апа безне ачык йөз белән каршы алды. Ул безгә Антон Чеховның "Каштанка" әсәре турында сөйләде. Бу әсәрдә сүз зур шәһәрдә югалган эт баласы турында бара. Каштанка адашып йөргән вакытта аны бер цирк артисты табып ала һәм өенә алып кайта. Яңа хуҗа эткә карата бик мәрхәмәтле була. Яңа урында Каштанкага рәхәт булуга карамастан, ул үзенең беренче хуҗаларын күрүгә, алар янына кайта. Әлеге әсәр безне тирә - ягыбыздагы булган хайваннарга карата мәрхәмәтле, дусларга тугры һәм безгә яхшылык эшләгән кешеләрне онытмаска өйрәтә.

Ул көнне "Каштанка" әсәренең авторы, язучы Чеховның туган көне иде. Шул сәбәпле без китапханәдә Рузилә апа белән аның турында белемнәребезне ургаклаштык. Китапханәдә очрашу бик күңелле һәм файдалы булды.

***Инсаф Закиров, IV сыйныф укучысы***






## Авылыбызның тарихи күперләре

Түбән Майна җирләренең Чирмешән елгасының ике ягында да урнашуы сәбәпле аның тирәсендә күперләрнең булуы табигый. Авылыбыз биләмәләре аркылы Чирмешәннең кушылдыклары булган дистәгә якын эреле-ваклы инешләр агып төшә. Алар аркылы чыгып йөрү өчен дә элек-электән күперләр салынып килингән. Хәзерге вакытта аларның күбесе инде юкка чыгып беткән. Бары тик урыннары һәм атамалары гына билгеле. Күперләрнең күпчелеге авылдан көнбатыш тарафтагы инеш һәм елгалыклар аркылы Биләр юлы өчен салынган булган. Әлеге юлдан Биләргә Түбән Майна халкы гына түгел, Кыдырата, Әдәмсуы, Такталы кешеләре дә йөргән. Узган гасырның 90нчы елларына чаклы Түбән Майна – Биләр юлыннан бик еш йөрелгәнлектән, ул күперләр даими рәвештә төзәтелеп, яңартылып торды. Хәзерге вакытта Биләр юлы файдаланылмау сәбәпле, бу күперләр барысы да череп һәм җимерелеп беттеләр.

**Олы күпер**

Олы күпер авыл барлыкка килгәннән алып 1980 нче елларга чаклы даими торгызылып һәм файдаланылып килгән. Авыл биләмәләренә Чирмешән елгасының ике ягындагы җирләр дә кергәнлектән, Олы күпернең әһәмияте зур булган. "Олы" дип сыйфатлануы үзе үк күпернең дәрәҗәсен белдереп тора. Олы күпернең төп урыны Мәхсет елгасы тамагы һәм Сарҗинат куаклыгы беткән турыда. XVIII гасыр ахыры һәм XIX гасыр уртасы карталарында Олы күпер шул урында күрсәтелгән. Тирә-яктагы авыллардан Горкага баручы юллар шул күпер аркылы үткән. 1970нче еллар башында Олы күпер яңа урынга – 100 метрлар түбәнгәрәк күчерелә. Хәзер ул урын күпердән калган берничә имән субайдан һәм махсус сөзәкләндерелгән ярлардан беленеп тора.

1730 нчы еллардан алып Олы күпер безнең авыл өчен генә түгел, ә төбәк күләмендә әһәмияткә ия була башлый. Шул елларда Казанда кораблар төзү өчен урман әзерләү Кама арьягы урманнарына да җәелдерелә. Казанга агач ташыла торган юлларның берсе безнең иске авыл аркылы үткән. "Лашман юлы" дип аталучы бу юл Чуаш Әдәмсуы ягыннан Мәхсет һәм Кәрәкә елгалары арасындагы кыр буйлап сузылып, Олы күпер аркылы Иске авылга килеп кергән. Авыр йөк төягән йөзләгән олаулар үтүдән Олы күпер дә еш тузган һәм аны даими яңартып торырга кирәк булган. "Олы күперне лашманчылар салган" –дигән хәбәрләр шул заманнардан калганлыгы аңлашыла.

Язгы ташу алдыннан Олы күпернең бүрәнәләре сүтелеп, калку урынга ташып куела иде дә, ташу кимегәннән соң яңадан җыела иде. Олы күпердән файдалану 1980нче еллар уртасына чаклы дәвам итте һәм шул дәвердән соң ул башка торгызылмады. Үз вакытында аның аркылы К-700 кебек авыр тракторлар да чыгып йөри ала иде.

**Икесаз күпере**

Авылга иң якын урнашкан бу күпер әле бүгенге көндә дә файдаланууда. Исеменнән күренгәнчә, Икесаз күпере шул исемне йөрткән инеш аркылы чыгып йөрү өчен хезмәт итә. Элек ул агачтан салынган булган. 1980нче еллардан алып трактор арбасы тимерләреннән эшләнгән хәлдә тора.

**Нәмәт бабай күпере**

Биләр юлы белән Зур чирәм болыны һәм 9 гектарлы кыр аркылы үткәннән соң "Нәмәт бабай елгасы" дигән елгалыкка килеп чыгасың. Бу атама хәзер авылда яшәүче Нигъмәтуллиннар һәм Габдуллиннарның нәсел башы булган Нигъмәтулла бабайдан калган. Ул бабай Биләр юлының әлеге елгалык аркылы үтә торган җиренә күпер салган булган. Шушы игелекле эше аның исеме елга һәм күпер атамасына әверелеп, әле дә зекер ителә. Нигъмәтулла бабайның 1835-1911нче елларда яшәвен исәпләсәк, аның күпер салуы 1860-1880нче елларга туры килә. Ләкин ул урында күпер аңа кадәр дә салынган булырга тиеш. Чөнки ул елгалык аркылы язын-көзен һәм яңгырлы җәйләрдә күперсез чыгу мөмкин түгел. Хәзерге вакытта ул турыдан йөрүче гомумән юк дисәң дә була.

**Мәхсет күпере**

Чуаш Әдәмсуы авылы ягындагы кырлардан башланып, Тирмән алды куаклыгы беткән җирдә Чирмешәнгә коючы инеш "Мәхсет елгасы" дип атала. Бу инешнең Биләр юлы узган җирдәге чокыры тирән булганлыктан, ул урынга шактый зур күпер салына иде. Элек ул күпергә Әдәмсуы авылыннан Биләргә бара торган юл да килеп тоташкан булган. Моны без югарыда китерелгән 1854нче елгы картадан күрә алабыз. Мәхсет күперенең 1990нчы еллар башыннан соң яңартылганы булмады. Аңардан истәлек булып елгалык аркылы сузган озын имән агачы гына калган. Хәзерге вакытта Мәхсет елгасы аркылы торба салып ясалган буадан йөрелә.

**Кәрәкә күпере**

Шәмә урманыннан башланып, Тукморза куаклыгы аркылы Чирмешәнгә коючы инеш "Кәрәкә елгасы" дип атала. Биләр юлы уза торган турыда Кәрәкә инешенең ярлары сөзәк һәм сазлыклы. Аның аркылы күпернең 1880нче еллар башыннан алып салынганы юк. Шул дәвердән алып, бүгенге көнгәчә Кәрәкә күпере торба салып ясалган буадан гыйбарәт.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***